ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.06.2021 г. Заинск № 394

**"Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү" буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2020 елның 06 февралендәге 53 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

«Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 19 декабрендәге 433-ФЗ номерлы Федераль закон, «Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2020 елның 31 июлендәге 373 номерлы Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. "Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү" буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2020 елның 06 февралендәге 53 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында мәгариф өлкәсендә вәкаләтләрне аныклау турында нигезләмә кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 пунктның 1 пунктчасы 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;»;

1.2. Текст буенча «Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында" Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 30 августындагы 1014 номерлы боерыгы" сүзләрен «Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2020 елның 31 июлендәге 373 номерлы боерыгына» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Л.Р. Печина
3-27-42